ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлегенең Татар Әйшәсе ав. торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

17 октябрь 2022 ел № 2

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, “2023 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм торак пункт территориясендә даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз ) сум күләмендә үзара салым кертергә һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авыл җирлегенең Татар Әйшәсе ав. торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ яшьтәге кешедән җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны түбәндәге эшләрне:

1) вак таш сатып алу һәм Татар Әйшәсе зиратының подъезд юлларына вак таш җэю.

2. Лампаларны сатып алу һәм урнаштыру.

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»

дигән сорау буенча 2022 елның 12 октябрендә 9 сәгать 30 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 115 (йөз унбиш) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 65 кеше, бу 56,89 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"ӘЙЕ" позициясе өчен гражданнар җыенында 66 (алтмыш биш) катнашучы тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 (ноль) катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Иске-Казан авыл җирлеге Татар Әйшәсе ав. торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыенының нәтиҗәләре – дөрес дип танырга.

2. 2023 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Иске-Казан авылы җирлеге Татар Әйшәсе ав. торак пунктында яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум (биш йөз) суммада үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча юнәлтергә:

1) вак таш сатып алу һәм Татар Әйшәсе зиратының подъезд юлларына вак таш жэю.

2. Лампаларны сатып алу һәм урнаштыру.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Г.Р.Закирова